# Татар теле һәм әдәбияты укытучысы - 2006 конкурсы

Дәрес эшкәртмәсен
әзерләде:
Гыйләҗева Фәния
Нурсәхи кызы

Самара шәһәре
«Яктылык»
мәктәбенең югары
категорияле татар
теле һәм әдәбияты
укытучысы



«И мөкаддәс моңлы сазым!
уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен,
айрылабыз ахрысы!

Шат яратса да
җиһанга ят яраткан раббысы».

"...Саз мой нежный и печальный,
слишком мало ты звучал.
Гасну я, и ты стареешь...
Как расстаться мне с тобой?


Создал Бог ее веселой,
но мирской тщете чужой."

# Хәерле көн, агачлар!

# Хәерле көн, кошлар!

# Хәерле көн, табигать!

# Хәерле көн, кунаклар!



# Тема: «Табигать һәм кеше» (дәрес - эзләнү)

**Максат:**

1. **Лексик тема буенча бәйләнешле сөйләм телен камилләштерү.**
2. **Укучыларда туган як табигатен ярату хисе һәм аны сакларга омтылыш тәрбияләү.**
3. **Экологик культура һәм патриотик тәрбия бирү.**

## Эзләнүнең проблемалары:

1. **«Табигать нәрсә ул?» дигән сорауга җавап эзләү.**
2. **Әйләнә-тирәнең кеше белән бәйләнешен ачыклау.**
3. **Табигатьнең экологик хәле.**
4. **Нәтиҗә чыгару.**

## Эзләнү этаплары:

1. **Табигать – туендыручы.**
2. **Туган якның гүзәллеге.**
3. **Табигать-анага һөҗүм.**
4. **Табигать-анабызны саклыйк!**

***Эпиграф: Табигатьне саклау – Ватанны саклау ул.***

***М.М. Пришвин***

Җ

Җилбер-җилбер йөрмәс
идем,
Җил тавышын сизмәсәм.
Өзелеп җырлар язмас
идем,
Үз халкымны сөймәсәм.

(Г. Тукай)

Ч

Өйгә кергән чыпчык,
Очып йөри чып-чып.
- Чыпчык, чыпчык,
Чык, чыпчык.
Очып чык, чыпчык,
Чык, чыпчык!
Чык, чык, кошчык, очып
чык!

# Сүзлек өстендә эш

«Табигать» сүзенең берничә мәгънәсе бар.

- Кешене чолгап алган, аның эшчәнлегеннән тыш барлыкка килгән табигый материаль дөнья. Жир планетасы.
- Билгеле бер урынның жир-сулары, үсемлек һәм хайваннарның дөньясы.
- Өстен көч. Тәңре (Ходай) мәгънәсендә.
- Табигать – характер.

- Экология – (грек сүзе) «Ойкос» – йорт, ә «логос» - фән дигәнне аңлата, ягъни яшәгән урының, йортың турындагы фән.
- «Экология» сүзен беренче тапкыр 1886 елда немец галиме Эрнест Геккель үзенең«Гомуми морфология» дигән хезмәтендә кулланган.

# Туган якның гүзәллеге
# (Р. Миңнуллин «Елның дүрт төсе»)

Яратам мин
ап-ак төсне.
Бөтен дөнья
ап-ак төсле-
Шундый якты, шундый
нурлы-
Бөтен дөнья ак кына…
Ап-ак була белә шулай
Безнең туган як кына.



Яратам мин зәңгәр
төсне
Бөтен дөнья зәңгәр
төсле-
Зәңгәр күчә күзләргә-
Күккә карап ят
кына…
Зәңгәр була белә
шулай
Безнең туган як
кына.





Яратам мин

сары төсне.

Бөтен дөнья

сары төсле.

Саргайган яфраклар

җиргә

Сарылалар чак кына…

Сары була белә шулай

Безнең туган як кына.



Яратам мин

яшел төсне.

Бөтен дөнья

яшел төсле.

Яшел дулкын чаба

кырда,

Җил иссә дә чак

кына…

Яшел  була белә

шулай

Безнең туган як кына.

# Табигатьнең экологик хәле




Бака: Кешеләрнең рәхимсезлегенә чик-чама юк. Без бакаларны бер дә сөймиләр, төрлечә рәнҗетәләр. Югыйсә, без зарарлы бөҗәкләрне юкка чыгарабыз.

Чыршы:һәр Яңа ел алдыннан куркудан дерелди үк башлыйм.

Каен: Ә мин яз көне зар елыйм. Минем тәнемне нәрсәләр белән генә тишмиләр дә, ничек кенә җәрәхәтләмиләр. Бәйләп, ярамны дәвалап китәргә дә оныталар тагын.

# Бу гүзәллек яшәрме?



Җир елый,  ишетәсеңме?
Мин ишетәм!
Челтерәп аккан чишмәләрем
Нигә кипкән?
Җир елый, ишетәсеңме?
Мин ишетәм!
Сандугачлы талкайларны
Кемнәр кискән?
Табигатьне  кемнәр шулай
Әрәм иткән?
Кешеләрдә миһербанлык
Кая киткән?
Җир елый, ишетәсеңме?
Мин ишетәм!
Бу гүзәллек, бу  җир шары
Яшәр микән?

( Э. Афзалова)


# Табигатькә һөҗүм

Кеше, үзеңнең нәпсеңне тый, табигатьтән күпне сорама, югыйсә, ярык тагарак кырыенда калырсың!



Кош-корт, җәнлек, үсемлекләр,
Бетәбез дип торганда,
Бирешмәскә булганнар.
Саклар диеп, яклар диеп,
Аңа кереп тулганнар.










1948 елда халыкара табигатьне саклау берләшмәсе даими комиссия оештыра. Англия зоологы Питер Скотт тәкъдиме белән халыкара «Кызыл китап» булдырыла. 1966 елда сирәк очрый торган үсемлек, хайван исемнәре теркәлә башлый.

«Кызыл китап» СССРда 1974 елда булдырыла, ә Россиядә 1983 елда чыгарыла.


«Яшәү өчен кояш, ирек һәм кечкенә генә чәчәк кирәк», - дигән бөек әкиятче Ганс Христиан Андерсен.
Кеше, соңлый күрмә!
Акылыңа кил!
Яңгырый экологик набат!
Кеше, уйлан кабат-кабат!